# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге совхоз бистәсе торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**11 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ атарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 11 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:. 2023 елда Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Воровский торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) -Воровский торак пункты Яр буе урамы, Овражная урамы территориясендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау (юлны планлаштыру, балчык, ком тутыру, таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 350 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 177 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 177 кеше тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге совхоз бистәсе торак пунктында халык җыены узуын таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен - гамәлдә дип санарга.
2. Сорау буенча карар кабул ителде дип таныргa: 2023 елда Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Воровский торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм

алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) -Воровский торак пункты Яр буе урамы, Овражная урамы территориясендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау(юлны планлаштыру, балчык, ком тутыру, таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Воровский исемендәге авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә. http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Воровский исемендәге
авыл җирлеге башлыгы урынбасары Мифтахова З.Ф.